# КАРАР

**2022 елның 25 ноябре** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Нормабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндә санап кителгәннәрдән кала:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 яки аннан да күбрәк баласы булган әниләр;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары» - һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- Нормабаш авыл клубын ремонтлау һәм карап тоту, түбә һәм тәрәзәләрне алыштыру; (проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Нормабаш авылының Вахитов урамы юлларына вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Нормабаш авылында Вахитов урамы буенча 5 нче урам яктырту линиясен үткәрү (материал сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- һ. Такташ урамы буенча газүткәргечне узгәртү (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Нормабаш авылы зиратын карап тоту һәм инвентарь сатып алу (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Су башняларын карап тоту, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу (проект-смета документларын эшләү материал сатып алу, килешү буенча түләү)

- Урамнарны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);

- Нормабаш авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорларда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 72 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 37.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 37 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны:«2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндә санап кителгәннәрдән кала:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 яки аннан да күбрәк баласы булган әниләр;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары» – һәр балигъ булган кешедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- Нормабаш авыл клубын ремонтлау һәм карап тоту,(түбә һәм тәрәзәләрне алыштыру; проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Нормабаш авылының Вахитов урамы юлларына вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Нормабаш авылында Вахитов урамы буенча 5 нче урам яктырту линиясен үткәрү (материал сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- h. Такташ урамы буенча газүткәргечне үзгәртү (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Нормабаш авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү (кораллар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Суүткәргеч челтәрен һәм су башняларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (артезиан скважиналары өчен насос сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Урамнарны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);

- Нормабаш авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорларда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип таныырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Кәримуллин